БАЛА ҮЗ РИЗЫГЫ БЕЛӘН ТУА

Эльмира Зарипова гаиләләргә күрсәтелгән ярдәм турында сөйләде

> 2

САРМАН САНДУГАЧЫ

Зөһрә Сәхәбиева үзенең якташы һәм моңдашы турында истәлекләрен барлый

> 3

СОҢГЫ УТЫРЫШ

Дәүләт Советы депутатлары бюджет һәм җирле үзидарәләрнең киләчәге турында сөйләште

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 189 (28771) | Шимбә | 25 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Эльза

Богдан

Илфат

СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАРНЫҢ ӘТИ-ӘНИЛӘРЕ:

«ХЫЯЛЛАРНЫ БАЛАЛАРГА ТАКМЫЙБЫЗ»

Бүген өлкәннәр яшьләрне, телефонда утыра, укырга да, берни эшләргә дә теләмиләр, дип ачулана. Алай булгач, бер минут та буш вакытлары булмаган бу балалар кайдан килгән? Татарстан Президентының Чыршы бәйрәменә сигез меңнән артык сәләтле укучы җыела. Алар арасында укуда, спортта, иҗатта, иҗтимагый тормышта уңышка ирешкән, шулай ук авыр хәлле гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар да бар.

Өч яшьтән – «укучы»

Эльза Абдрахманова 9 нчы сыйныфта укый. Ул – «Җиңү волонтеры» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Чаллы бүлеге волонтеры, «Нур» яшьләр үзәгендә координатор. Аның уңышларын санап бетерерлек түгел. КФУның халыкара багланышлар бүлегенә укырга керергә хыяллана.

– Кызыбыз тугыз айдан тәпи йөри башлады. 1,5 яшьтән бакчага бирдек. Әбисе укытучы булгач, 3 яшьтән үк хәрефләр өйрәтергә тотынды. 5 яшьтә укый-яза белә иде инде, – ди әнисе Руфинә Абдрахманова. – Эльзада элегрәк «отличник синдромы» дигән нәрсә булды. Бу яктан үземә охшаган. 7 нче сыйныфларда «дүртле» алуны бик авыр кичерә башлады. Барысын да яхшылап аңлаттык, тынычланды. Күбрәк гуманитар фәннәрне ярата. Холкы бик тыныч, үзенә тәнкыйди яктан бәя бирә белә.

Әнисе үзе җыр укытучысы булгач, кызын 6 яшьтән музыка мәктәбенә укырга биргән. Эльза җырларга, биергә дә оста. Музыка мәктәбен тәмамлагач, аның буш вакыты күбрәк кала башлый. 8 нче сыйныфта «Ореон» балалар оешмасына языла. Анда төрле проектларда катнаша.

– Ватанпәрвәрлек хисе көчле аңарда. Сугыш ветераннарына барып, хәлләрен белешәләр, аларга булышалар. «Без – ветераннарны күрүче соңгы буын бит», – дип әйтеп тә куя кайчак, – ди Руфинә ханым.

Богдан, син татарча белергә тиеш!

Богдан Кизимга – 13 яшь, Бөгелмәнең лицей-интернатында 7 нче сыйныфта укый. Ул – «Бөгелмә скаутлары» үзиреклеләр отряды җитәкчесенең уң кулы. Быел бөтенроссия экология акциясе кысасында узган «ZeroWaste» («Ноль отходов») бәйгесендә беренче урынны алган. Президентның Чыршы бәйрәмендә беренче тапкыр катнашуы икән.

– Минем һәр минутым – исәптә. План буенча яшәргә өйрәндем. Интернетта утырырга вакыт юк. Унлап түгәрәккә йөрим. Араларында робот техникасына бәйлесе дә бар. Юк, арымыйм. Көнгә ике мәртәбә әти-әниемнең хәлен белешеп алам. Минем хәлләр тәртиптә, дим, – дип сөйли Богдан. – 5 нче сыйныфтан волонтер булдым. Кешеләргә яхшылык эшләү бик ошый. Волонтерлык тормыш рәвешемә әйләнде. Бөгелмәдә тернәкләндерү үзәге бар. Анда еш барабыз, авыру балаларга ярдәм итәбез. Бүләкләр бирәбез. Аларны төрле уеннарга өйрәтәбез. Төрле мастер-класслар оештырабыз. Районнардагы истәлекле урыннарны өйрәнәбез.

Богданның иң яраткан дәресе – технология, әлеге фәннән олимпиадаларда катнаша. Үзен сәләтле бала дип саный. Булачак һөнәрен әлегә сайламаган. Спорт белән дус. Биш ел кикбоксинг белән шөгыльләнгән. «Атна ахырында әти-әниемне сагынып, өйгә кайтам. Анда яраткан этем белән мәчем дә көтеп тора. Хайваннарны кызганам», – дип сөйләде Богдан. Үз холкын бәяләве дә кызык тоелды. «Бәлкем, мин вакчылрактыр, ләкин иң яхшы сыйфатым – сер саклый белү», – дип, елмаерга мәҗбүр итте.

Сүзгә әнисе Екатерина кушылып: «Богданны бакчада татар төркеменә бирдек. Татарстанда яшәгәч, син татар телен белергә тиеш, дидек. Кибеттәме, башка җирдәме – югалып калмасын, татарлар белән аралаша алсын. Шуннан артыгын таләп итмибез. Без үзебез – рус милләтеннән. Бераз гына татарча аңлыйбыз. Мәктәптә дә Богдан туган тел буларак татар телен өйрәнә. Телләр белү бернәрсәгә дә комачауламый. Лицейда төрек, инглиз, француз, татар телләрен өйрәтәләр. Монда бәйге аша үтеп, үзе теләп барды. Лицейда тәрбия эше бик дөрес куелган. Балаларның кирәкмәгән эш белән шөгыльләнергә вакытлары юк. Без үзебезнең хыялларны балаларга такмыйбыз. Богданның үзенә нәрсә ошый, шуның белән шөгыльләнә. Өй эшенә, укуга да катнашмыйбыз, бары журналдагы билгеләрне генә күзәтәбез», – ди.

Куян белән көрәш

Азнакайдагы 9 нчы мәктәпнең 11 нче сыйныф укучысы Илфат Миңнегалиев – көрәшче егет. Көрәш буенча Россия җыелма командасы әгъзасы, төрле бәйгеләрдә җиңүче.

– 4 яшьлек чагында улыбыз зур куянны тәгәрәтеп, аударып уйный башлады. Көрәшкә һәвәслеге шуннан ук күренә иде. Улымны ияртеп, тренировкага йөртә идем. Башкаларның бил алышканын күреп, аның да теләге уянды. 6 яшьтә мин алып барган түгәрәккә йөри башлады, – ди Илфатның әтисе, «Юбилейный» спорт мәктәбе директоры Айрат Миннегалиев. – Гәүдәсе бик кечкенә иде. Биле, тезе авырткан чаклары да булды, тик көрәшкә кул селтәмәде. Дөрес туклана, авырлыгын контрольдә тота. Үз кумирлары бар, шулар кебек көрәшергә омтыла. Максатлары зур – Татарстан, Россия чемпионы булу. Идел буе спорт һәм туризм академиясенең көрәш бүлегенә укырга керергә җыена. Максатчан, алдашканны яратмый. Үзе белән дөрес итеп сөйләшкәнне ярата. Авыр булса да, туры юлдан гына барырга тырыша.

Сәрия МИФТАХОВА

Теләкләр чынга аша

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Алексей Песошин, депутатлар парламент сессиясе алдыннан «Теләкләр чыршысы» Бөтенроссия хәйрия акциясендә катнашты. Алар чыршыдан балаларның теләкләре язылган открыткаларны алды. Теләкләр якын араларда тормышка ашырылачак. Акция инвалид балаларга, ятимнәр, аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр, шулай ук каты авырулардан интегүче өлкәннәргә ярдәм итү максатыннан оештырылган. Татарстаннан 2 мең кеше үзләренең хыялы турындагы открыткаларны проектның «елкажеланий.рф» сайтына юллаган.

Рөстәм Миңнеханов өч баланың – Казанда яшәүче тугыз яшьлек Олегның (пеноблоклар җитештерү заводын барып күрергә тели), Чаллыдан ун яшьлек Камилнең (танк йөртеп карамакчы) һәм 15 яшьлек Екатеринаның (ноутбуклы булырга хыяллана) хыялын үтиячәк. Фәрит Мөхәммәтшин Спас районында яшәүче уналты яшьлек Евгенийның хыялын тормышка ашырачак. Үсмер инде берничә ел буе дүрт кыллы гитарада (укулеле) уйный, махсус курсларга йөри, әмма әлегә үзенең музыка коралы юк икән.

Бөтенроссия хәйрия акциясендә бөтен ил: сәясәтчеләр, җәмәгать эшлеклеләре, Россия геройлары, артистлар, гади кешеләр катнаша. Акция 15 ноябрьдә башланып, 2022 елның 28 февралендә тәгәлләнәчәк.

tatarstan.ru

60тан яшьрәкләрне тикшерәләр

Татарстанда яшәүчеләр өчен янә диспансеризация һәм медицина тикшерүләре башланып киткән. Бу хакта сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтте. Аның сүзләренә караганда, сырхауханәләрдә 60 яшькә кадәрге кешеләр кабул ителәчәк. Өлкән яшьтәгеләр әлегә медицина тикшерүе уза алмый. Шул ук вакытта министр урынбасары искәртеп узганча, COVID-19 инфекциясен кичерүчеләрне җентекләп тикшерүнең бер көнгә дә тукталганы юк. Исегезгә төшерәбез: Татарстанда ноябрь башыннан, коронавирус инфекциясенең яңа дулкыны башлану сәбәпле, балалар һәм олыларга диспансеризация үткәрү туктатып торылган иде.

Яңа һөнәргә өйрәнгәннәр

Быел Татарстанда 5,3 меңнән артыграк эшсез ихтыяҗ зур булган һөнәрләргә бушлай өйрәтелгән. Тагын 6 меңнән күбрәк кеше «Демография» илкүләм проекты буенча һөнәр үзләштергән. Кешеләр башлыча сак хезмәткәре, электр, газ белән эретеп ябыштыручы, машина йөртүче, ягулык салу станциясе операторы, тракторчы, тегүче, пешекче, лаборант, хисапчы кебек һөнәрләргә өйрәтелгән.

Ә инде «Демография» илкүләм проектының «Мәшгульлеккә ярдәм итү» федераль проекты кысасында 50 яшьтән өлкәнрәкләр, пенсия алды яшендәгеләр яңа һөнәрле булган. Моннан тыш 3 яшькә кадәрге бала карау ялындагы хатын-кызлар, мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган эшсез аналар төрле курслар узган. Һөнәрле булырга теләүчеләрдән гаризалар «Работа России» порталында кабул ителә.

Быелга тәмам

Казанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре тәгәлләнә. Билгеле булганча, алар башкаланың барлык 7 районында оештырылды. «Салават күпере»ндә яшәүчеләр өчен Осиново бистәсендә ярминкәләр узды.

Шул ук вакытта киләсе елның февралендә икмәк һәм үсемлек маеның кыйммәтләнүе көтелә. Бу хакта «Известия» Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына таянып яза. Бәяләрнең чама белән 2 процентка үсүе күздә тотыла. Он хакы ноябрьдәге белән чагыштырганда 2,9 процентка артып, тоннасы 24,6 мең сумга җитәргә мөмкин. Бодай оныннан пешерелгән икмәк, 2,1 процентка кыйммәтләнеп, 43 сум булачак. Ә инде үсемлек мае бәясе 2,2 процентка артып, килосы 137,4 сум тәшкил итәчәк. Сүз уңаеннан, 1 декабрьдән шоколад-кәнфит бәяләре арткан.

COVID-19

Чир нәрсәгә өйрәтте?

Татарстанда гриппка бәйле вазгыять шәптән түгел. Белгечләр әйтүенчә, быел вакцина күләме дә азрак булган, ясатучылар да азрак. Хәзер инде чирләмәс өчен сакланып йөрергә киңәш итәсе генә кала. Аның каравы, соңгы ике айда коронавируска каршы вакцина ясатучылар күп булган.

Белгечләр белән коронавируслы вазгыятькә кагылышлы матбугат конференциясе гриппка бәйле вазгыятькә канәгатьсезлек белдерүдән башланды. Планлаштырылган 60 процент урынына халыкның 26 проценты гына прививка кадаткан. Хәзер инде вакцина ясату тәгәлләнгән.

– Быел гриппка каршы вакцина без көткән кадәр күләмдә һәм вакытында кайтартылмады. Хәзер инде саклык чараларын үтәргә киңәш ителә, – диде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина. – Гриппка бәйле вазгыять куандырырлык түгел. Авыручылар саны кимеми. Хәзер ул эпидемиологик чиктән 35 процентка артыграк. Барлыгы 272 очрак теркәлде. Соңгы атнада – 118. Аның каравы коронавирус белән гриппның бергә кушылуы күзәтелми.

«Таҗ»лы хәлгә кире кайтсак, республикада авыручылар саны 40 процентка кимегән. Декабрь белән ноябрьне чагыштырсак, чирләүчеләр саны 1,8 тапкыр азрак.

kzn.ru

Вакцина ясатучылар санына килгәндә, елның соңгы ике аенда 1 млн 150 мең кешегә коронавируска каршы прививка кадаганнар. Шул рәвешле хәзер аларның саны 2,27 миллионга җитте. Күмәк иммунитет дәрәҗәсе дә – 74,5 процент. Бу – әйбәт күрсәткеч, диләр.

Шулай да, «омикрон» һөҗүмен көтәсеме? Аны булдырмас өчен чаралар җитәме?

– «Омикрон» штаммы Татарстанга кергән очракта, яңа чикләүләр кертергә җыенмыйбыз. Республикада гамәлдә булган чикләү чаралары теләсә нинди штаммга каршы нәтиҗәле. Куркырлык берни дә көтелми.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН, Казан мэры:

Өч балам да ипотека түли. Моның бер ояты да юк – фатирын да, машинасын да, башкасын да эшләп алсыннар. Чит илләрдә 30ар ел, пенсиягә чыкканчы ипотека түлиләр. Нью-Йорктагы, Истанбулдагы кебек яшисебез, ә фатирны 3 елда аласыбыз килә.

(Журналистлар белән очрашуда сөйләгәннәрдән)

РОССИЯДӘ – МАШИНА ЙӨРТҮЧЕЛӘР

«Авто.ру» хезмәте машина йөртүчеләрдән юлда үзләрен ничек тотулары турында сорашкан. Кайсылары кагыйдәләргә буйсына, кемнәр аларны санга сукмый?

Юлда үземне тәртипле тотам	79%
Үземне әдәпле машина йөртүче дип санамыйм	14%
Юл кагыйдәләрен белү җитә, этикет кагыйдәләренә исем китми	7%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Без әле кая барабыз?

Яңа 2022 елга аяк басарга санаулы көннәр калды. Футурологлар, ягъни үткәнне һәм бүгенгене анализлап, киләчәккә фаразлар ясаучы белгечләр, XXI гасырга шактый оптимистик күзлектән караган, өметле фаразлар кылган булуга да карамастан, яңа йөзьеллыкта без үткән 21 ел аларның бик үк хаклы булмавын раслый кебек.

Бүгенге дөньяга, төрле яктан ишелеп килгән мәгълүматка, без яшәгән тарафларга карап, җиһан яңа Урта гасырларга кереп бармыймы, дигән сорауны куясы килгән вакытлар да була. Антик дәвер юкка чыккач яралган елларга түгел, ә чорга, заманга яраштырылган яңа Урта гасырларга. Башкача уйлаган өчен кешене мәйданнарда баганага бәйләп җәзалаулар булмас анысы. Тик яңа инквизиция килергә бик тә мөмкин. Ул инде юлга чыкты да төсле. Чөнки хокуклар һәм ирекләр дигәндә күп ил-җирләрдә артка китеш күзәтелә. Шул ук Кытайның миллиард ярым халкы үтә каты авторитар режим астында бүген. Тик бу хәлләр – әле бәланең бер ягы гына. Урта гасырлар дию шуннан: безгә уңайлыклар китерүче технологик алгарыш рухи алгарышны чикли, хәтта гарипли. Болай да саклык белән генә алга барган рухиятне технологияләр үсеше кирегә бора, дисәм дә хата булмас.

Кайбер галимнәр XXI гасырга чыккан кешелекне постинтеллектуаль җәмгыять дип атарга өлгерде дә инде. Технологияләр катлаулана барган, аларны өйрәнү, белү хаҗәте арткан саен, кешелек моңарчы дөньяда тупланган белемне үзләштереп бетерә алмый башлады. Шуңа бүген бар өлкәләрдә дә диярлек тар белгечлек өстенлек итә. Моның бер яхшылыгы да юк. Бигрәк тә гуманитар як читтә калганда, санга сугылмаганда. Без сабак алырга тиешле тарихта да, гасырлар буе җыелып килгән әдәбият җәүһәрләрендә, бөек философларның хезмәтләрендә дә ашкын дөньяның хәзер эше юк. Ә бит үз өлкәсен генә белгән тар белгеч ул – биологик робот. Бүгенге программист, башканы әйткән дә юк, үзе көн буе чекерәеп баккан компьютерның эчен, төзелешен белми, белергә дә теләми. Пластмасса тышлык эчендәге микросхема, плата, детальләрне ул, ничә тапкыр ишеткәнем булды, берләштерелгән исем белән «железки» дип атый. Фәлсәфә, тарих аның өчен гомумән дә «Terra incognita». Гомуми медицинаны белмәгән теш табибы, автомобиль двигателенең эш принцибын аңламаган инженер – андыйлар булган җәһәттә дә, теләсә кайсы белгечкә гуманитар өлкәне дә билгеле бер дәрәҗәдә үзләштерү кирәктер. Шунсыз бәндә дә, җәмгыять тә рухи яктан үсә алмый бит.

Без хәзер гомумән дә аңлаешсыз чорда яшибез. Укытучыдан да хәзер хезмәт күрсәтүче ясадылар. Ул баланы тәрбияләми. Аның аңа вакыты да юк. Баланы ата-ана да тәрбияләми хәзер. Аларның да вакыты юк, алар бүгенге тизлек заманында дөнья куа, акча эшли. Алар бүген – тәэминатчы. Баласын ул кием-салым белән, акча, гаджетлар белән тәэмин итә, ашата, тик тәрбияләми. Дәүләт тә тәрбияләми яшьләрне. Дәүләт төрле юллар белән патриотизм сеңдерергә тырыша, тик начарны яхшыдан аерырга өйрәтми. Бала-чага, үсмерләрне интернет, урам мохите, субкультура тәрбияли. Бүген андый тәрбиянең нәтиҗәләрен күрәбез. Кайчак үтә дә аянычлыларын. Ә бит безгә чаклы яшәгәннәр, киләчәк буыннарга дип, асыл музыка үрнәкләре, укып туймас әдәби әсәрләр, карап туймас картиналар, кабатланмас сәнгать әсәрләре калдырган. Аларда кешелек маяк итәргә тиешле югары әхлак, шәфкать, батырлык – һәммәсе бар. Яшь буын шул дөньяда яшәргә, иң беренче чиратта шулар аша тәрбияләнергә тиеш. Юк, ашкын кешелек яшәгән саен югары кыйммәтләрдән читләшә, ваклана, меркантильләнә. Һәм шул рәвешле яңа караңгылыкны, Урта гасырларны якынайта, үз киләчәген дә шик астына куя.

Аңлаешсыз, хәтта ки гаделсез чор. Алыпсатар, футболист, артист университет профессорыннан күбрәк алган җәмгыять хакында нәрсә, нинди яхшы сүз әйтергә була? Ул алга, яхшыга таба бара аламы? Андый җәмгыятьнең, гомумән, киләчәге бармы? Достоевскийга кагылышлы язманы әзерләгәндә, берничә чыганактан иң күп тиражлы язучыларны (иң күп укылучы китап авторларын) барлаган идем. Беренче урында беләсезме кем? «Король ужасов» исеме алган Стивен Кинг! Гавам менә нәрсә укып юана бүген. Аңа китапның да ял иттерә, күңел ачтыра, дөньяны оныттыра торганы булсын. Уйландыра, нәтиҗәләр ясата торганы түгел. Бу да деградация – затсызлану билгесе түгелме?

Җәмгыятьтә кыйммәтләр алышынып ята. Яхшы белән начар буталып бетте. Урлашып, кеше алдап, гламур тормышта яшәгәннәр өскә калыкты. Тормыш олимпына менгәннәр барысы да шундый чыбыктан үрелгән димим, тик андыйлар күп. Яшьләр социаль челтәрләр аша шулар тормышын карый, шулай яшәргә хыяллана. Аларның аңына акрынлап ялтыравык тормышка ирешүдә «все средства хороши» дигән фикер өлгерә. 20–30 яшьлекләр авызыннан ничә тапкыр «Тормыштан барысын да алып калырга кирәк» дигән сүз ишеткәнем булды. Ягъни күбрәк күңел ачарга, мөмкин кадәр күбрәк матди байлык җыярга, азрак эшләргә. Умыра алган кадәр умырырга! Алучылар җәмгыяте. Ә кем бирергә тиеш? Роботлаштырылган цехлар ясаганны йөртүчесе булмаган машиналар синең өеңә ташырга тиешме? Технологик прогрессның кешене эшсез итә, тамашага, күңел ачуга этәрә торган ягын мин аңлап бетермим. Нәкъ менә хезмәт маймылдан кеше ясаган, ә эшне онытып, күңел ачып яшәүгә корылган тормыш аны яңадан агач башына менгермәсме?

Кешелеккә, илләргә берләшеп, технологик алгарышны чикләү, аның җиһанга, бәндәгә зыянга эшли торган юнәлешләрен туктату турында уйлар вакыт җитмәде микән? Без әле бу юлы табигатькә салынган зыян, океан төпләрен тутырып килүче пластик, киселеп бетеп баручы урманнар, углекислота аркасында туган глобаль җылыну турында сөйләшмибез. Анысы – аерым тема. Без бүген рухи, мәдәни караңгылыкка таба алынган юнәлеш хакында чаң кагабыз. Бүген, атомны иярләү, микроэлектроника заманында, ни гаҗәп, бернинди белем таләп итми торган һөнәрләр барлыкка килде. Һәм андыйларның хәтсезе гыйлемле зат гомердә дә күрмәгән байлыкка ия. Шул ук футболчы, хоккейчылар. Спорт, җанатарлар, ярышлар булмасын дип беркем дә әйтми. Тик туп типкән кешенең еллык кереме 100 млн сум булырга тиеш микән? Фән докторы аена 40–50 меңгә эшләп йөргәндә. Рухият үссен дигәндә, тамаша, аны күрсәтүчеләр, спортчымы ул, гламур җырчымы, цирк клоунымы, беренче позицияләрдә торырга тиеш түгел. Шул вакытта гына «Инстаграм» ише челтәрләр андый кавемне – ялтыярга, кыланырга, кыланмышлар белән мактанырга яратканнарны пропагандалау урыны булмаячак…

Без тарихтан Яңарыш чоры, Мәгърифәт чоры (эпоха Возрождения, эпоха Просвещения) дигән, бер үк дәвергә диярлек туры килгән заманнарны беләбез. Ягъни караңгы Урта гасырлардан соң, яңадан гыйлемгә, рухи алгарышка кайту, югалтканнарны яңадан булдыру чоры. Дөньяга бөек философларны, математикларны биргән беренче демократия ватаны Борынгы Греция ирек-мөмкинлекләрен, Квинт Гораций кебек шагыйрьләре, Птолемей кебек астрономнары, Тацит кебек тарихчылары булган Борынгы Рим казанышларын торгызу дәвере булган ул Яңарыш чоры. Кешелек акылына кайткан дәвер. Тик технологияләр зиһенен томалаган яңа Караңгылыктан соң яңа Яңарыш килмәскә дә мөмкин бит. Үз хаҗәтләрен генә белгән, кеше эгоизмын яңа баскычка күтәргән, табигатьне санламаган техноген җәмгыять үзе утырган ботакка балта чаба-чаба аны нык юкартты инде.

Кешелеккә кешечә яшәргә өйрәнәсе иде.

tatarstan.ru

БЫЕЛГА МЕНӘ ШУЛ

24 декабрьдә парламент быелның соңгы утырышын уздырды. Көн тәртибендә мәсьәләләр артык күп түгел иде. Зур эшләрне ел ахырына калдырмау әйбәт инде ул.

Республика бюджетына үзгәрешләр кертү турындагы закон проектын тикшерү дә шома гына узды. Бәхеткә дип әйтикме, бюджетның керем өлеше 40,1 млрд сумга артачак. Шуның 22,1 миллиарды – салым һәм салым белән бәйле булмаган керем акчасы. Мәскәүгә дә рәхмәт инде, федераль бюджеттан 18 млрд сум кергән һәм бурычка түгел.

Финанс министры Радик Гайзатуллин бюджет үтәлешенә уңай бәя бирде һәм, керемнәрнең артуы бюджетның чыгым өлешен 27,1 млрд сумга арттырырга мөмкинлек бирәчәк, диде. Һәрхәлдә, фараз шундый. Гомумән алганда, Татарстанның 2021 елга бюджет кереме – 359,4 млрд сум, ә чыгым өлеше 350,9 млрд сум булыр дип фаразлана. Бюджет кытлыгы 13,1 млрд сумга кимер дип көтелә.

Бюджет, салым һәм финанслар комитеты рәисе Леонид Якунин әйтүенчә, бу ел дәвамында икътисад аякка басу өстенә, күп күрсәткечләр буенча пандемиягә хәтле дәрәҗәне узып киткәнбез.

Чыгыш ясаучылар республика бюджетының социаль йөзле икәнен әйтергә дә онытмады. Шулай була күрсен киләчәктә дә, дип әйтүебез. Чөнки соңгы елларда тормыш бер алдын, бер артын күрсәтә. Аңлавыбызча, тәҗвирус зәхмәтенең дә тиз генә бетәсе юк. Аңа каршы көрәшү өчен казнадан өстәмә 14 млрд сум акча бирәчәкләр. Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджетына да өстәмә 5 млрд сум кергән. Димәк, чыгым өлешен дә арттырырга мөмкинлек бар дигән сүз.

Утырыш менә шулай матур гына, тыныч кына барганда, Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин Россия Дәүләт Думасы советыннан килгән бер закон проекты белән таныштырды. Әлеге проект гавами хакимиятнең бердәм системасына җирле үзидарәгә кагылышлы үзгәрешләр кертү турында иде. Кыскача гына әйткәндә, сүз муниципаль берәмлекләрне кыскарту турында бара. Аерым торак пунктларда җирле үзидарәнең территориаль органнары яшәп калыр һәм авыл җирләрендә старосталар барлыкка килер. «Бәхил бул, силсәвит!» була инде.

Дөрес, җирле үзидарәнең бүгенге системасын яшәтү өчен 2025 елның сентябренә хәтле вакыт бирелә, ә аннан соң 2028 елга хәтле күчеш чоры билгеләнәчәк, ди. Шуннан соң нәрсә була? Проектта язылганча, муниципаль районнар, муниципаль округларга кереп, үз йөзләрен югалтачаклар.

Утырышта әлеге закон проектының бөтен нечкәлекләре турында сөйләшү, фикер алышу булмады. Бәлки депутатларыбыз 205 битле документ белән танышырга да өлгермәгәндер. Президент Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, бездә үзидарә системасы сынау узган, камилләшеп беткән иде. Әлбәттә, федераль закон проектын нигез итеп алырга тиешбез, әмма аңа үзгәрешләр тәкъдим итәргә кирәк. Фәрит Мөхәммәтшин эшче төркем төзеп, кичекмәстән эшли башлау ягында. Закон проекты хәзергә Дума советыннан төбәкләргә генә җибәрелгән, ә яңа елда думачылар аны карый да башлаячак. Шуңа күрә әйтеп калсак, хәзер әйтеп калабыз инде.

Әлеге закон проекты шактый ыгы-зыгы чыгарыр кебек. Альберт Хәбибуллин әйтүенчә, ул закон көчен алса, республика законнарын да тагын бер кат карап чыгарга тиеш булабыз, 107 федераль законга үзгәрешләр кертергә дә туры киләчәк. Виктор Черномырдин исән булса, бәлки: «Кычытмаган җирне кашымагыз!» – дигән булыр иде. Без алай ук дип әйтә алмыйбыз шул, әмма үз фикеребезне җиткерербез дип өметләник.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

БУРЫЧЛАР ҮЗГӘРМИ

Фәрит Мөхәммәтшин Дәүләт Советының быелгы эшчәнлегенә йомгак ясады. Аның әйтүенчә, COVID-19 инфекциясе, элеккечә үк, республика һәм Дәүләт Советы өчен җитди сынау булып кала. «Әмма вазгыятьнең катлаулылыгына карамастан, Дәүләт Советы, республиканың калган барлык хакимият органнары кебек үк, аралашуның барлык ысулларын кулланып, үз эшен дәвам итте, – дип билгеләп үтте ул. – Мондый чаралар парламентның эшкә сәләтен саклау, республикадагы, башка төбәкләр, федераль үзәк һәм чит илләрдәге коллегаларыбыз белән элемтәләрне югалтмау мөмкинлеге бирде», – диде ул.

Быел Татарстан парламенты 10 утырыш уздырган. Аларда 284 мәсьәлә каралган. Дәүләт Советы 94 закон кабул иткән. Комитетларда, фракцияләр һәм депутатлар төркемнәрендә, гадәттәгечә, күп эш башкарылган. Дәүләт Советы комитетлары каршындагы экспертлар советлары законнар эшләүгә зур өлеш керткән. Бер ел эчендә аларда барлыгы 238 мәсьәлә каралган.

Парламент башлыгы узган сайлау кампаниясе чорында халыктан җыелган теләк-тәкъдимнәргә аерым тукталып үтте. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, быел 5,5 меңнән артыграк наказ кергән. Шәһәр-авылларда яшәүче төрле яшьтәге кешеләр үзләренең тәкъдимнәрен ирештергән. Хәзер депутатлар һәм башкарма хакимият органнары наказларны үтәү белән мәшгуль.

Казанның 175 нче гимназиясендәге фаҗигадән соң Россия законнарына үзгәрешләр кертү буенча 7 закон инициативасы, шулай ук Дәүләт Советының Россия Хөкүмәте Рәисе һәм Дәүләт Думасы Рәисе исеменә 3 мөрәҗәгать эшләнгән. Дәүләт Думасына закон инициативасы тәртибендә 7 федераль закон проекты кертелгән.

Татарстан парламенты җитәкчесе депутатларның һәм республика Хөкүмәтенең актив эшләвен билгеләп үтте. «Кертелгән закон проектларының 90 проценттан артыграгы бу, – диде ул. – 4 закон проектын республика Президенты тәкъдим итте, Үзәк сайлау комиссиясе һәм Татарстан Прокуроры – 1әр закон проекты кертте».

Дәүләт Советы җитәкчелеге һәм комитетлар исеменә халыктан 8100 мөрәҗәгать алынган. Шул исәптән 5410 хат – интернет-кабул итү бүлеге аша.

Парламентның алдагы эшчәнлегенә килгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, көйле, системалы законнар чыгару эше төп бурыч булып кала. «Алга таба да катлаулы шартларда профессиональ эшләячәкбез, икътисадны торгызуга һәм Татарстанда яшәүчеләрнең керемен арттыруга ярдәм итәчәкбез, – диде ул. – Илкүләм үсеш максатларына ирешү, илкүләм проектларны тормышка ашыру, һичшиксез, өстенлекле юнәлешләр булып тора».

Чир нәрсәгә өйрәтте?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тест үткәреп торабыз, Татарстанда әлегә «омикрон» штаммы юк. Ул-бу була калса, обсерватор әзер, андый очракларда нишләргә икәнен беләбез, тәҗрибә дә бар, – диде Любовь Авдонина.

Сүз уңаеннан, күптән түгел Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы коронавируска каршы «Мир-19» дигән яңа препаратны теркәде. Ул 18 яшьтән алып 65 яшькәчә, авыр хәлдә булмаган сырхауларны дәвалау өчен билгеләнгән. Татарстан да бу даруны көтә. Хәзерге вакытта аңа бәйле вазгыятьне күзәтәбез, диләр.

– Тотып караган даруыбыз түгел. Безгә дә килеп ирешсен, карарбыз, куллану инструкциясен өйрәнәчәкбез, – диде Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков. – Булган мәгълүмат ниндидер нәтиҗәләр ясау өчен җитәрлек түгел.

Елга йомгак ясарга күп калмады.

– 2020 ел изоляция чараларына бәйле булса, бу ел вакцинация шигарендә узды. Быел авыр хәлдәге сырхаулар күп булды. Бәйрәм яллары вазгыятькә артык төзәтмәләр кертмәс дип өметләнәм. Хәл тотрыклангач, ятаклар санын киметтек. Яңа елга да шулай керербез дип ышанасы килә. Яңаларын җәелдерерлек булмасын иде, – диде Любовь Авдонина һәм халыктан аңлы булуларын үтенде.

Владимир Жаворонковның да киләсе елга өмет-хыяллары шундыйрак. Медицина тармагы өчен киеренке ел булуын әйтеп торасы да юк.

– Без әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә тизрәк җавап бирергә һәм аңа бәйле карарларны да тизрәк кабул итәргә өйрәндек. 2021 ел безнең өчен авырулар күплеге белән кыен булды. Бу бөтен нәрсәдә чагылды: реанимациядәге ятакларда да, кислородка ихтыяҗда да, – диде ул. – Безнең медицина хезмәткәрләре үз бурычларын үтәде. Аларга рухи яктан авыр булды.

БӘБИ ТАПСАҢ, АКЧА БАР

Узып баручы ел социаль өлкәдә иң күп түләүләр белән истә калачак. Быел республика халкына 22,8 млрд сумлык ярдәм күрсәтелгән. Дәүләт тарафыннан кайгыртуның күп өлеше бала үстерүче гаиләләргә туры килгән. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сөйләде.

tatarstan.ru

– 1980 еллар тарихта хатын-кызларның декрет ялына китү белән истә калса, 2021 ел акчага бай булды. Моңарчы хөкүмәт тарафыннан гаиләләргә бу кадәр ярдәм күрсәтелгәне юк иде әле, – диде ул. – Киләсе елда да ярдәм дәвам итәчәк. Гыйнвар аеннан минималь хезмәт хаклары арта. Аның күләме Россиядә 13890 сум булса, Татарстанда бу сумма 16700 сумны тәшкил итә.

Эльмира Зарипова сүзләренчә, республикада эшләүче оешмалар белән килешү төзелеп, Татарстан минималь хезмәт хакы күләмен үзе билгели. Киләсе елдан яшәү минимумы күләме дә артачак. Ул 10750 сумга җитә. Шул рәвешле, сабыйларга тиешле пособиене алу тәртибе дә үзгәрә. Беренче сабыен алып кайтучылар өчен гаиләнең кереме (әти, әни, баланы исәпләп) 70344 сумнан ким була икән, алар балага 3 яшь тулганчы 10756 сум күләмендә пособие алачак. 7 яшькәчә сабыйлар үскән гаиләләрдә җан башына 10750 сум акча чыкмый икән, алар да пособиегә өметләнә ала. Кеременә карап, аларга яшәү минимумыннан 50, 70, 100 процент күләмендә пособие түләнә. Киләсе елдан әлеге ярдәмгә опекага бала алган гаиләләр дә өметләнә ала. Шулай ук күп бала үстерүче, беркайда да эшләмәүче әти яки әни, гаилә аз керемле саналган очракта, сабыйлары өчен бу акчаны алачак.

2022 елда сирәк авыру белән интегүче балаларга да өстәмә акча бирелә башлый. Эльмира Зарипова әйтүенчә, Татарстанда шундый 500 бала бар. Яңа елдан аларга ай саен 1815 сум акча түләнәчәк.

– 2022 елда үз эшен ачарга теләгән гаиләләргә күрсәтелә торган ярдәм күләме арта. Элек андый гаиләләргә дәүләттән 75 мең сум бирелсә, Президент Рөстәм Миңнеханов карары белән бу сумма 150 меңгә җиткерелде. Әлеге акча бер генә тапкыр бирелә. Булышуның максаты – үзмәшгуль булып теркәлгән гаиләне аз керемлелектән чыгару. Татарстанда бу ярдәмгә өметләнүче 200 гаилә бар, – ди министр. – Тагын бер яңалык. Элек авыл җирендә яшәп, үз эшен башларга теләүчеләрнең кереме булып пай җирләре исәпләнә иде. Киләсе елдан ул хакта мәгълүмат кирәк булмаячак.

Министр, газ кертүдә дә дәүләт ярдәме булачак, ди. Бөек Ватан сугышы ветераннары, физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр, аз керемле гаиләләр дәүләттән бирелә торган 80 мең сумга өметләнә алачак. Тагын бер үзгәреш – пенсионерлар һәм бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә ял йортларына бирелә торган юлламаның бер көне элек 800 сум булса, хәзер 1297 сум булачак.

– Киләсе елдан әкренләп кәгазь боткасыннан арыначакбыз. Министрлыкка караган хезмәтләр буенча «Социаль казначылык» дигән бердәм портал эшләячәк. Кешеләр бер гариза белән, өйдән дә чыкмыйча, 18 төрле дәүләт хезмәтен алачак. Әйтик, күпбалалы гаилә таныклыгы аласы, ди. Моның өчен әллә нинди документлар әзерлисе булмый. Порталдагы мәгълүматларга нигезләнеп, аны ясап та бирәчәкләр. Инвалидлык алу өчен дә бер гариза җитәчәк. 2025 елда исә барлык төр социаль хезмәтләрне бер гариза белән алу мөмкинлеге барлыкка киләчәк.

Тагын бер яңалык – тиздән «Ата-ана фидакарьлеге» («Родительская доблесть») дигән медаль бирелә башлаячак.

– Әлеге медальне җиде һәм аннан күбрәк бала үстерүче гаиләләргә тапшырачакбыз. Тик бер шарт бар – гаиләдә бер генә бала булса да 18 яшькә җитмәгән булырга тиеш, – ди Эльмира Зарипова.

Очрашуда министр аз керемле гаиләләр өчен барлыкка килгән социаль контракт турында да сөйләде. Илкүләм «Демография» проектына да тукталды. Әлеге проект кысасында башкарылган эшләр арасында тагын бер яңалык – хәзер өйдә ялгыз гына калдырып булмаган өлкәннәргә социаль хезмәт оешмаларыннан 4 сәгатьлек ярдәм күрсәтеләчәк.

– Акыл ягыннан зәгыйфь балаларны тормышка өйрәтү проекты дәвам итә. Быел безгә Президент зур ярдәм күрсәтте. «Идел» тернәкләндерү үзәгендә андый балаларны яшәргә өйрәтәбез. Алар 3 ай дәвамында пешерергә, кибеткә йөрергә, юарга һәм башка бик күп эшләргә өйрәнәләр. Киләсе елдан биредә яшәү һәм өйрәтү вакытын 6 ай итәргә җыенабыз. Бу балалар әти-әниләренә терәк була алмаса да, олыгайгач, тормыш итәргә әзер була, – ди ул.

Очрашуда, киләсе елда дәүләт түләүләренә кызыгып, бала табучылар артырмы икән, дип тә сораштык. Министр сүзләренчә, республикада беренче баланы табарга атлыгып тормыйлар. Шуңа да ул бәби-бумны 2004–2005 елда туган балалар үсеп җитеп, гаилә коргач кына көтәсе дигән фикердә. Әмма аның әйтүенчә, хәл начар түгел. Татарстанда өченче сабыен табучылар арткан. Икенче бала алып кайтучылар 39 процентны тәшкил итә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯКТАШЫМ-МОҢДАШЫМ

Адәм балалары кебек үк, авыллар, төбәкләр, хәтта шәһәрләр дә аерым, үзгә холыкка ия. Җырларда җырлана торган Сарман ягы кешеләре дә башкалардан аерылып тора.

Без бер-беребезне үзеңнән кечерәкләргә яратып бәйтә торган «апаем»нардан, тел белгечләре бик яратып бетерми торган «дагын», «дәген»нәрдән генә түгел, тоемлап кына була торган әллә кайсы гына хасиятләрдән дә танып алабыз. Язучыларыбыз, галимнәребез һәм, әлбәттә, җырчыларыбыз, музыкантларыбыз, композиторларыбыз бар! Моңлы-гамьле халык җырларын җырламаган, күңелендә моң йөртмәгән кеше бик аздыр безнең якта. Юкка гынамы «Сарман» сүзен көйгә төргән никадәр җыр туган халык җанында! Сарман төбәгендә канат үстереп, башкалага карап очкан, Сарман ягы кешеләренә хас асыл сыйфатларны үзендә туплаган җырчы сандугачыбыз Зөһрә Шәрифуллина турында берникадәр сүз әйтмәкче булам.

Беренче күрүдә Зөһрә миңа Сарман тугайларында үсеп утырган тәрле төстәге болын чәчәкләре арасында шытып чыккан чәчәктәй тоелды. Тавышының үзенә ае-рым, беркем белән буташтырмаслык булуы, халыкчан җырлау манерасы белән бергә, ул игътибарымны репертуар сайлаудагы төпле карашы, зирәклеге һәм талымлылыгы белән дә җәлеп итте. Танышлыгыбыз башында якташ кызым файдасына бу зур бер «плюс» иде. Алга китеп шунысын әйтим: иҗатының башлангыч елларында репертуар мәсьәләсе сәнгать советы иләге аркылы уздырылып хәл ителсә, соңрак, сәнгать советлары юкка чыккан соң да, Зөһрә Шәрифуллина мәгънәсез җырларны беркайчан да җырламады, үзе булып калды. Бүген колакта «аныкы» гына булып яңгырап торган җырлары исә алсак, алар тәрбияви көчкә ия, ата-анага, гаиләгә угланы, һәр җир кешесенә якын бала чакны, яшьлекне сагынуга, олы мәхәббәткә, тугрылыкка, җirне гомумкешелек кыйммәтләрен зурлауга багышланган җырлар булыр. Беренче башкаручысы Зөһрә Шәрифуллина булган бик күп шундый җыр халык арасында киң таралу алды.

Зөһрәнең Түбән Кама музыка училищесын тәмамлап, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә килүен бик яхшы хәтерлим. Нәкъ безнең яктагыча олыны – олы, кечене кече итә белүче, җыр сәнгатенә гашыйк бу кыз белән якын дуслар булып киттек. Үз язмышың сөйләм теле күңелемә якын булганга, аның сөйләшкәнен рәхәтләнеп, җаннарым эреп тыңлый идем. Бер филармониядә эшләсәк тә, озын-озак гастроль араларында аерылышып тора, ә кайткач сагынышып очрашып сөйләшә, киңәшләшә идек, чөнки без гомер буена диярлек күршеләр булып яшәдек. Беренче алган фатирларыбыз да, икенчеләре да бер үк йортларда булып чыкты. Бер-беребезгә ярдәмле булып, гаилә дуслары булып яшәдек. Зөһрә, гомумән, ярдәмчел, аерылыкка юлыкканга үзе белеп, үзе аңлап ярдәм кулы сузарга ашыга торган кеше ул. Мәрхүм хәләл җефетем, Хәйдәрем, олуг җырчы Хәйдәр Бигичев һич тә уйламаганда, бик кисәк, бик яшьли бу дөньядан киткән төндә, өйгә беряшләшп әйләнеп кайтканда, улым белән икебез яшен суккандай тораташ басып торган мәлдә бусагабыздан беренче булып атлап кергән һәм: «Без бер-бер нәрсә эшли алабызмы?» – диген кеше Зөһрә яктәшым, Зөһрә күршем, Зөһрә туганым булды. Алар, Азат белән бергәдер дип уйлыйм, Казанның икенче читеннән бертуган Миндесорур апамны алып килделәр ул төнне. Мондый ярдәмне ничек онытасың?! Кеннеңкем иконен беләсен килсә, өч көннек юлга чык, дигән сүз дә бар. Зөһрә белән байтак юлларны бергә уздык, бәйрәмнәрдә, башка җырлы тамашаларда катнаштык.

Зөһрәнең яшьлегендә сайлаган яры Азат белән гомер бүйларына сәнгатькә, халыкка хезмәт итүләре да сокланычы. Безнең һөнәр бала табып үстерү өчен бик күп киртәләр куя торган хезмәт, моны шул юлны – һич читенсенмичә әйтәм, батырлыкка тиң юлны узганнар гына белә. Азат белән Зөһрә гаиләсендә акыллы, тәрбияле ике ир бала үсте. Гомумән, алар тормышта «без» дип күкрәк какмыйча, ихласлык белән яшәүче, сәхнәдә кулга-кул тотышып иҗат итүче матур пар булдылар, әле дә шулай.

Еллар буе юлда йөреп, тәгәрмәч өстендә яшәп, һәрдаим халык күз алдында булган концерт җырчысының тормышы тәгәрмәч өчендә бөтерелгән тиенне хәтерләтә. Көн-төн иҗат белән яну, репетицияләр, телевидение һәм радио өчен яңа язмалар әзерләү, тапшыруларда, очрашуларда катнашу, гастрольләр вакытында туктаусыз юлда булу, күчеп йөрү, көн саен уңайлы-уңайсыз яңа урында куну, һәр көнне яңа сәхнә, яңа тамашачы алдында имтихан тоту… Җырчының сәхнә артындагы мәшәкате дә тавык чүпләп бетерерсез, язып аңлатырлык түгел… Менә шушы бөтен авырлыкларны җиңеп күтәргән, шул ук вакытта җырчы буларак «форма»да калган кеше генә сәхнә тота ала. Безнең Зөһрәбез – шушы юлдан тигез атлап баручы бик тә тырыш, акыллы, тынгысыз, батыр кызыбыз. Татар дәүләт филармониясенең эстрада булеге-ндә эшләгән елларында ул үз бригадасында төп җырчы – солистка буларак концерт эшчәнлеген СССР диген зур илебезнең бөтен киңлегендә алып барды. Бригада җитәкчесе булу – коллективтагы һәр кеше өчен җавап бирүдән башлап, ул вакытта бик зурдан куела торган керем планын үтәү дигән сүз дә. Ул – бу вазыйфаны җиренә җиткереп башкарып килгән җырчы хатын-кыз. Үзенең концерт бригадасына алып, кулланган яшь башкаручыларга зур сәхнәгә күтәрелү өчен юл ачуы, тәҗрибә туплага булышуы – шулай ук бик зур игелек!

Сарман сандугачы, милли моңны ана сөте аша сеңдергән, халыкның борынгы җырларын иҗатының тамыры иткән, композиторларыбыз һәм шагыйрьләребезнең уртак иҗатыннан әнҗе саналырлык җырларны сайлап җырлаучы затлы җырчы, Татарстанның халык артисты Зөһрә Шәрифуллинаның җыр сәнгате дөньясында тоткан үз урыны, зур урыны бар.

Күп еллар буена үз халкына ихлас хезмәт иткән, татар мәдәниятенә саллы өлеш керткән, халык мәхәббәтен казанган кабатланмас җырчыбыз бу көннәрдә бик матур юбилеен билгеләп үтә. Килачәктә дә халкыбызны сөендерел яшәү насыйп булсын! Милләттәшләребез, сәхнәдәшләребез, газета укучылар да шул ук теләкләр дип беләм.

Зөһрә СӘХӘБИЕВА,
Татарстанның халык артисты

КОТЛЫЙБЫЗ!

Казан шәһәре Идел буе районының «6 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары **Вәлиева** Дилара Равил кызына, «Казан шәһәре халыкара мәктәбе» автоном коммерциягә булмаган гомуми белем бирү оешмасы директоры **Гафиятуллин** Нияз Мансур улына, «Татарстан Республикасы Буа шәһәре лицей-интернаты (сәләтле балалар мәктәбе)» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Җамалетдинов** Рамил Миннеһади улына, Казан шәһәре Мәскәү районының «Казан федераль университеты каршындагы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Миначева** Раилә Зәфәр кызына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Яңа Арыш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Нәбиуллин** Дамир Хатыйп улына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлангыч белем бирү буенча белгече **Хаҗиева** Энисә Нәкыйп кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Нефтеконсорциум» ябык акционерлык җәмгыяте баш технологы **Бариев** Артур Рафис улына, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Мәдәни үсеш үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең чуваш фольклор коллективы җитәкчесе **Ракова** Наталия Ильиничнага, «АЛТЫНДОРСТРОЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайнуллин** Айрат Хасип улына, «РАМ-СТРОЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Галимҗанов** Рамил Наил улына, «РАМ-СТРОЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте инженеры **Галимҗанов** Ренат Наил улына, «РАМ-СТРОЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галиуллин** Рамил Илдар улына, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе торак төзелешен координациялау бүлеге баш белгече **Ларин** Сергей Ивановичка, Татарстан Республикасының «Татинвест-гражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештеру фирмасы» дәүләт унитар предприятиесенең 3 номерлы архитектура-планлаштыру остаханәсе баш инженеры **Латыйпов** Артур Рафаэль улына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Алеева** Ирина Павловнага; «Акыл үсеше ягыннан артта калган балалар өчен Дербышки балалар йорты-интернаты» дәүләт казна учреждениесенең административ-хуҗалык тәэминаты буенча белгече **Мөләкова** Гөлфәрия Хәмзәкаи кызына; «Нәкәр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының производство буенча урынбасары **Саликов** Илсур Мирзанит улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Салихов** Илгиз Хәйдәр улына, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе керем ведомстволарына хезмәт күрсәтү бүлеге башлыгы **Дяглюк** Венера Миназыйм кызына, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе 23 номерлы бүлеге башлыгы **Мифтахов** Мансур Мәгъсүм улына, Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары **Шашкин** Алексей Геннадьевичка, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе 24 номерлы бүлеге башлыгы **Якимова** Любовь Петровнага, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 14 номерлы районара инспекциясе хокук бүлеге башлыгы **Демахина** Флера Әлфәт кызына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе банкротлык процедуралары тәэмин итү бүлеге башлыгы **Зазвонова** Ольга Борисовнага, «Содружество» акционерлык җәмгыяте генераль директорының күчмалыксызлык буенча урынбасары **Ельченков** Андрей Николаевичка, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы **Латыева** Татьяна Юрьевнага, Төбәк хезмәттәшлегенә булышлык итү һәм үстерү Татарстан фонды идарәче директоры **Малыгина** Людмила Владимировнага, Төбәк хезмәттәшлегенә булышлык итү һәм үстерү Татарстан фонды баш бухгалтеры **Тарасова** Ирина Леонидовнага, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесенең мәгълүмат белән эшләү һәм шәхси белешмәләрне эшкәртүне оештыру буенча урынбасары (медицина-социаль экспертиза табибы) **Софронов** Александр Валерьевичка, «Пенза өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Туктаров** Җиһанша Зәйнәтулла улына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Шакирова** Лена Миясәр кызына, Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы урынбасары, таможня хезмәте полковнигы **Хренов** Валерий Витальевичка, «Б.И. Тихомиров исемендәге «Казан Гипронииавиапром» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: 7 номерлы бүлекнең әйдәүче инженеры **Бушмарева** Светлана Сергеевнага, 8 номерлы бүлек инженеры **Гайфетдинов** Шамил Фәрит улына, 8 номерлы бүлек инженер-конструкторы **Ежов** Вадим Олеговичка, 33 номерлы бүлек башлыгы **Раков** Олег Викторовичка, генераль директорның үсеш буенча урынбасары **Сотников** Леонид Александровичка, генераль директорның мәгълүмат технологияләре буенча урынбасары **Шәйхиев** Марат Кирам улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

«Азнакай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең район ветеринария лабораториясе ветеринария табибы-токсикологы **Гайсина** Җәмилә Минһаҗетдин кызына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе ветеринария эшен оештыру бүлеге башлыгы **Ильина** Елена Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«АЗНАКАЙ» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Урманай» товарлыклы-сөтчелек фермасының яшь терлек караучысы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Абдуллин** Мөгамбәр Мөгави улына, «Игенче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте товарлыклы-сөтчелек фермасы сыер савучысы (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Абдуллина** Гөлия Исмәгыйль кызына, «Таллы Бүләк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы сыер савучысы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Әхмәтова** Илмира Мөнир кызына, «Синицин Андрей Анатольевич» крестьян (фермер) хуҗалыгы терлекчелек бригадиры (Татарстан Республикасының Спас районы) **Вәлиуллин** Ришат Мингали улына, «Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бозау караучысы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Гәрәфиева** Фирдәүзия Инар кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«П.В. Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Нуретдинов** Илгиз Әсфәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Восход – безнең йорт» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гомәров** Сәгыйрь Ясир улына, «Балтачның күптармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы производство предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең әйдәүче икътисадчысы **Закирова** Кадрия Мөбарәкша кызына, «Балтач районы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ибраһимов** Фәрит Нәкыйп улына, «Князево» торак милекчеләре ширкәте рәисе **Хафизова** Флюра Фәгыйть кызына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Волгадорстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры **Айзатуллин** Айрат Мансур улына, «Волга-Автодор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры **Шевырев** Станислав Вячеславовичка, «ТСИ» йортлар төзү махсуслаштырылган оешмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Галеев** Рөстәм Айрат улына, «Идея «Көньяк-Көнчыгыш» – төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Мәүлетбаев** Айрат Әсгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Шәхси эшкуар (Татарстан Республикасы Мамадыш районы) **Гаянова** Гөлнәзирә Рәфгать кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТаграС-ЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Азнакай электр энергиясе цехы челтәр районы башлыгы **Сеньков** Павел Леонидовичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры – бухгалтерлык исәбе һәм салым салу идарәсе башлыгы **Камалова** Гөлнара Наил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Совет районыннан алты бала (аларның бишесе өч яшькә җиткән) анасы **Вәлиуллина** Гөлнара Ринат кызы, Мөслим муниципаль районы буенча Мөслим авылыннан сигез бала (аларның җидесе өч яшькә җиткән) анасы **Кинарская** Светлана Проталионовна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава»** медале белән бүләкләнде.

***

Республиканың энергетика тармагын үстерүдәге мөһим казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен хезмәт ветераны **Макаров** Генадий Тимофеевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың энергетика тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Попудренко** Вәсилә Вазыйх кызы, республиканың сәнәгать һәм энергетика комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Хаҗиев** Рәүзил Мәгъсүмҗан улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Энергетика тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «2 номерлы Казан җылылык-электр үзәге» филиалы химик цехының суны химик әзерләү аппаратчысы **Габидуллина** Мария Викторовна **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7[1] статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 6 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Хисаметдинова Лилия Вәҗәһетдин кызына йөкләргә.
2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча 3 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Галләмова Дания Кәлимулла кызына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 24 декабре
№ 1254-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме сигезенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкару турында.
2. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 262-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.
3. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 40361-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
4. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Оренбург өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2021 елның 24 ноябрендәге 51/56-с номерлы килешүне раслау хакында.
5. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 261-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 260-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 255-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 258-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 253-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 263-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 256-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясына үзгәреш кертү турында» 254-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 257-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 249-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 251-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.
17. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
18. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
19. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе мәгълүматы.
20. «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 20281-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
21. «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 20492-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
22. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 20283-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын куллануддан керемнәрне бүлү нормативларын билгеләү хакында).
23. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 28408-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт бурычы һәм муниципаль бурыч составында Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гарантияләре һәм муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрне әлеге мәсьәләләрне бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетлары өчен бердәм хокукый җайга салуны билгеләү максатларында төгәлләштерү өлешендә).
24. «Россия Федерациясендә исәп-хисап башкарганда контроль-касса техникасын куллану турында» Федераль законның 2 һәм 4[2] статьяларына һәм «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 33099-8 номерлы федераль закон проекты турында (контроль-касса техникасын куллану тәртибе хакында).
25. «Экологик экспертиза турында» Федераль законның 11 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 11901-8 номерлы федераль закон проекты турында (яңа техникага, технологиягә техник документация проектларына дәүләт экологик экспертизасы ясау өлешендә).
26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 20280-8 номерлы федераль закон проекты турында (сәүдә урыны бирелгән затларның контроль-касса техникасын кулланмавына бәйле рәвештә базар белән идарә итүче компаниягә җаваплылык билгеләү хакында).
27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.10 һәм 27.11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 20308-8 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында эшләр буенча эш башкарганда тартып алынган законсыз әзерләнгән агачны реализацияләү, утильләштерү яисә юкка чыгару тәртибен билгеләү өлешендә).
28. «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 21281-8 номерлы федераль закон проекты хакында (кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпләү җайланмалары белән җиһазланырга тиеш булмаган объектлар исемлеген төгәлләштерү өлешендә).
29. «Россия Федерациясендә социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территорияләр турында» Федераль законның 34 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 33224-8 номерлы федераль закон проекты турында (социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территорияләр резиденты статусын төгәлләштерү өлешендә).
30. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законына үзгәреш кертү хакында» 28052-8 номерлы федераль закон проекты турында (товарны дистант ысулы белән сатканда кулланучыга сатучы хакында бирелә торган мәгълүматны киңәйтү турында).
31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 10316-8 номерлы федераль закон проекты турында (пассажирларны ташу маршрут картасыннан башка башкарыла торган транспорт чарасын тоткарлау мөмкинлеге хакында).
32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.17 статьясына үзгәреш кертү хакында» 23603-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юл транспортында гражданнарның үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен бозганы өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).
33. «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга һәм «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 33097-8 номерлы федераль закон проекты турында (халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм даими әзерлек хәлендә тотуның бердәм тәртибен билгеләү өлешендә).
34. 2021 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.
35. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 24 декабре
№ 1253-VI ДС

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г.) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:300303:193, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, с/т «Залесный», участок 72 выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка.
Заказчиком кадастровых работ является Суниева Бибинур Вафиновна, Республика Татарстан (Татарстан), г. Казань, ул. Осиновская, д. 27 корп. 1, кв. 15, тел.: +7 917 928-94-94.
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, с/т «Залесный», участок 72 25 января 2022 г. в 10 часов 00 минут.
С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.
Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 25 декабря 2021 г. по 24 января 2022 г. по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.
Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ:
16:50:300303:194, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, с/т «Залесный», участок № 73;
16:50:300303:179, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, с/т «Залесный», уч. № 58;
16:50:300303:178, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, с/т «Залесный», уч. № 57.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Извещение о необходимости согласования границ земельного участка

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:170111:258, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, СДТ «Наука», участок 39а, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка.
Заказчик: Саляхов Шамиль Дамирович, адрес: Респ. Татарстан, г. Казань, ул. Баки Урманче, д. 10, кв. 467, тел.: +7 (960) 048-46-55.
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 30 января 2022 г. в 9 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1.
Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.
Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:170111:259, 16:50:170111:257, 16:50:170111:1, расположены в границах кадастрового квартала 16:50:170111, Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, СДТ «Наука».
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границы земельного участка

Кадастровым инженером Дерябиной Марией Владимировной (420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, пом. 13б, mrczeo@mail.ru, +7-987-215-01-46), выполняются кадастровые работы по уточнению земельного участка с кадастровым N 16:50:221218:6, расположенного по адресу: РФ, Республика Татарстан, г. Казань, Авиастроительный район, ул. Серафимовича, дом 64/18.
Заказчиком кадастровых работ является Оглы Червоня Васильевич, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Беломорская, д. 84. тел: +79172680895.
Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ: 16:50:221218:7, расположенного по адресу: РФ, Республика Татарстан, г. Казань, Авиастроительный район, ул. В.Котика, дом 16.
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, пом. 13б 27 декабря 2021 г. в 11 часов 00 минут.
С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, пом. 13б.
Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 27 декабря 2021 г. по 28 января 2021 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 27 декабря 2021 г. по 28 января 2021г. по адресу: 420111, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ташаяк, 2а, пом. 13б.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24.07.2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности).

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

ТЫЛСЫМЛЫ БӘЙРӘМ

Кыш бабайга ышаныч, балачак «яра»лары, төрле маҗаралар – «ВТ» журналистларының балачак истәлекләрендә.

Бала чакта хәтерем бик әйбәт иде. Дүрт-биш яшьләрдә үк инде апалар артыннан озын-озын шигырь-поэмаларны отып ала, клубта үткән һәр бәйрәмдә шуларны сөйли идем. Яңа ел маскарадын да шигырь белән мин ачып җибәрәм. Билгеле, бүләк тә бирәләр. Аннан да бигрәк, бездә ул чакларда бу бәйрәмгә балаларны кертмиләр иде. Шигырь сылтавы белән мин ел да карыйм. Өченчедә укыган елны Яңа ел бәйрәмен укытучы булып эшли башлаган апам алып барды. Ул үз туганын катнаштыра дигән сүздән шикләнепме, шигырь сөйләргә Рәшит исемле малайга әйтте. Шулай итеп, мине бәйрәмгә алып бармадылар. Алар киткәч, елап, өйдәгеләрнең киләгән бирдем! Әби мескен, түзәр хәле калмагачтыр инде: «Әйдә бар», – дип, куып диярлек чыгарып җибәрде. Шактый ерактагы клубка йөгердем генә. Бәйрәм башланган. Бәхетемә, әни нәкъ ишек каршына утырган булып чыкты, тиз генә мине коридор аша сәхнә артына озатты. Елаклыгым аркасында, пәрдә арасыннан гына булса да, бәйрәм карадым. Аннан соңгы елларда барлык бәйрәмнәрдә дә мине катнаштырдылар, мәктәп тәмамлагач, күп еллар алып та бардым әле.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА



Икенче сыйныфта укыган чагым. 1975 елны каршыларга әзерләнеп йөрибез. Укытучыбыз Анастасия Ивановна сыйныфташым, дустым, партадашым Роза белән мине Яңа ел бәйрәменә Кәҗә белән Сарык булып киенеп, Габдулла Тукай әкиятен «сәхнәләштерергә» кушты. Миңа Кәҗә роле эләкте. Әй, яратмадык инде безгә шушы рольләрнең бирелүен! Янәсе, ничек инде ике «отличник»ка шундый ямьсез рольләр биреп була, дип, үзара гына тетмәсен теттек укытучыбызның. Әлбәттә, үзенә бер сүз дә әйтмәдек, кая инде олыларга, бигрәк тә укытучыга каршы дәшү... Нишләтәсең, пыр тузып, Кәҗә белән Сарык битлеген, киемнәрен әзерләргә тотындык. Битлекләрне матур гына итеп Розаның әтисе катыргыдан ясап бирде, карарак төстәге киемнәрне минем әни әзерләргә булышты.

Бәйрәм кичәсендә шул битлекләрне, тузга язмаган киемнәрне киеп, беркем танымаслык хәлдә чыршы янына килдек. Барысы да яратмыйча гына гел безгә карап тора кебек тоелды. Менә чыгыш ясарга вакыт җитте. Без Роза белән Кыш бабай янына килеп бастык та, үзебез дә көтмәгәнчә, менә дигән итеп рольгә кереп, тамаша карарга килгән әти-әниләрнең алкышларына күмелдек. Ачудан шулай килеп чыкты бугай ул... Шуннан ни булган дисез? Беренче урынны алдык! Яратмыйча гына тотынган эшебезнең ахыры әнә шулай бик әйбәт булып чыкты.

Бу истәлегем беренче укытучым Анастасия Ивановна Ефимованың рухына дога булып ирешсен.

Валентина СЕМЕНОВА

Беренчесе. Мин бәләкәй чакларда, күрше-тирәдә яшәүче бала-чаганы җыеп, күрәсең, азрак хәллерәк кешеләр булгандыр инде, өйдә Чыршы бәйрәме үткәрү гадәте бар иде. Ишетеп калсалар, апа-абыйлар, әби-бабайлар концерт карарга керә. Без булдыра алганча тырышабыз, аннан әни пешергән ләвешләр белән тәмләп чәй эчәбез. Бервакыт шулай әни безгә килгән балаларга икеләтә бәйрәм ясады: саубуллашып китеп барганда, һәрберсенең кулына кәгазь пакетка салынган Кыш бабай күчтәнәче тоттырды. Пакетның газета битләреннән ясалганлыгы бик тә хәтергә уелып калган. Шундук актарырга да тотындык. Эчендә витаминнар, кәнфитләр бар иде. Барыбыз өчен дә көтелмәгән сөенеч булды мондый бүләк. Бу хакта бала-чага озак сөйләнеп йөрде әле. Миңа исә бик рәхәт булды. Хәзер дә рәхәт.

Икенчесе. Сигезенче сыйныфта укыганда, Яңа елның соңгысы дип (мәктәбебез сигезьеллык кына иде), шау-гөр килеп әзерләндек бәйрәмгә. Сыйныфташым Илсөяр белән икебезне барлык класслар өчен дә алып баручы итеп билгеләделәр. Тамаша залында сөйли-сөйли, бии-бии, өч-дүрт сәгать басып торырга туры килде бугай. Кайткач, тегесе ничек, бусы ничек дип, әнидән сорашам. «Ии кызым, минем күземә берни күренмәде, төпчек кызым да үсеп буйга җитте дип, сиңа карадым да утырдым, нәрсә сөйләгәннәрен дә хәтерләмим, – диде әни. Сез булмагач, нишләп йөрим инде дип, мәктәп үткәргән бәйрәмгә башка бармады да кебек ул. Әнинең шушы сүзләре ничектер бер дә онытылмый. Яңа ел җиткәндә бигрәк тә калкыбрак чыга ул. Инде үз оныкларым үсеп җиттеләр, ә әниле Яңа ел минем күңелемне һаман да җылытып тора. Уйлап карасаң, нинди тирән мәгънә ята бит бу сүзләрнең төбендә. Ул – Ана мәхәббәте.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Авылда усал дип саналган, әмма олысы-кечесе хөрмәт иткән әти ничек иренмәгәндер, мин кечкенә чакта өйнең түренә гел чыршы куя иде. Мин дим, чөнки алтынчы балаларыннан соң мин, җиденчесе булып, сигез елдан соң гына туганмын. Апалар-абыйлар күбесе төрле шәһәрләрдә яшиләр, эшлиләр иде инде. Шул. Башы түбәгә тиеп торган чыршыны абый юнәтә, әти бизәүне үз өстенә ала иде. Бизәве дә гади генә түгел, чыршыга түшәмнән кыршау эленә, берничә әйләнәле ул кыршауда төрле-төрле гирляндалар җемелди иде. Ул гирляндаларның ниндиләре генә юк: шәм кебек, өй кебеге, йолдызлар, төнбоеклар, кар бөртекләре кыяфәтендәге... Әти аларны кыршауга да, чыршыга да элә дә, аннары билгеле бер тәртиптә янарга көйли. Утлары көйләнгәч, йолдызы беркетелгәч, чыршыга уенчыклар эләбез.

Уенчык элгәндә, кулдан төшеп китеп ватыла торган гадәте дә була. Аларны бер савытка җыеп барабыз. Чөнки безнең нәсел-нәсәп балалары укыган чорда мәктәпнең төп газетасын чыгара, андагы язуларны шушы чыршы уенчыкларын төеп бизисе була. Ялтырап торачак бит. Күңелле иде балачак! 9 яшемдәге Яңа ел тагын да күңелле булды. Әти чыршы тирәсендә туган көн үткәрергә рөхсәт итте. Февральгә хәтле тора да тора инде ул чыршы! Классташлар, урамдашлар килеп, сезнең чыршы мәктәпнекеннән биегрәк дигәч, әтинең дә күңеле булды кебек. Әни балаларга күчтәнәч пакеты таратты. Гел Яңа ел бәйрәме кебек булды ул, туган көн кебек түгел. Миңа да ошады.

Һәр кешегә үзенең балачагындагы Яңа ел әйбәтрәк кебек тоеладыр инде. Мандариннары да хуш ислерәк, кәнфитләре дә тәмлерәк, әйеме? Бәлки исәпле булганга кадерле дә, тәмле дә булгандыр ул. Хәзер бөтен нәрсә исәпсез, җиләк-җимеше ел әйләнә, бәлки шуңа тәмен дә сизмибездер.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Их, бу уенчыклар без кечкенә чакта булсамы? Ни генә юк хәзер бала-чагага! Чаба торганы да бар уенчыкның, очканы да. Сөйләштерә дә алар, йоклата да, уйната да. Тик уйнаучысы гына юк.

Зарланырлык түгел, шөкер, безгә дә эләкте уенчык. Артык уйнарга ятраткамын, ахры, берсе дә «исән» калмый иде. Өр-яңа машиналарның тәгәрмәчләре икенче көнгә үк пластилиннан әвәләнгән була, сынган урыннары изолента белән урала, кирәк икән кадак та кага беләбез. Бөтенләй кулга алырлыгы калмаса, өч тәгәрмәчле велосипедка тагып урам да әйләндерә алабыз. Кибеткә яңа уенчык кайтканчыга кадәр шул дәвам итә. Әни сөйли: машиналарны запаска дип икешәрне алып куйган чаклары да булган. Мавыгу, шуклыкның мондый нәтиҗәләре бераз үсә төшкәч дә бетмәде: кечерәкләргә миннән мирас булып велосипед-фәлән калганын хәтерләмим.

Әмма бер уенчыгыма башкаларга түгел, хәтта үзем дә кагылырга ярамады. Инде 34 ел буе полиэтилен пакетка төрелгән килеш саклана ул. Елга бер мәртәбә: Яңа ел җиткәндә чыршы астына төшеп утыра да, гыйнвар яллары тәмамлангач, кире шкаф өстенә менеп кунаклый. Әле СССР исемле дәүләт яшәгәндә – 1987 елның декабрь ахырында Зәй районының Чыбыклы урта мәктәбе гөрләп торган заманнарда беренче сыйныфны «бишле» билгеләренә генә тәмамлаган өчен бу юлларны язачак малайга авыл клубы сәхнәсендә кулын кысып тапшырылган мамыктан ясалган Кыш бабай сыны ул. Бездән соң килгән малай-шалайларга ирек нык бирелде. Әмма Кыш бабай һәрвакыт махсус сак астында булды. Мандаринсыз, аның каравы коронавируссыз, бургер һәм сушисыз, аның каравы ихлас һәм авылча, интернетсыз, аның каравы өмет һәм хыял тулы балачактан калган Кыш бабай ул. Аңа әле дә ышанырга була...

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Һәрбер бала кебек үк тылсымлы Кыш бабайга самими ышану сеңлем белән икебезнең күңелләргә кереп урнашкан чак.

Шулай беркөнне кич белән телевизор карап утырабыз. Әти белән әни мал-туар карарга чыгып киттеләр. Берзаман кемдер калын тавышы белән: «Э-һе-е-й, ачыгыз әле», – дип тәрәзә шакый. Барып карасак, үз күзләребезгә үзебез ышанмадык! Күпме Яңа елны чыршы төбендә сагалап та тота алмаган Кыш бабай каршыбызда басып тора! Шатлык катыш курку белән ишек ачып, Кыш бабайны түргә уздырдык, ул арада әни дә кереп җитте.

«Менә әле бөтен авыл буйлап балаларның хәлләрен белешеп йөри идем. Грипп белән авырмыйлармы, Яңа елга нинди тәртип белән кергәннәр, нинди һөнәрләре бар?» – дип, безнең кулга ике әфлисун тоттырды Кыш бабай. Ничек дулкынлануымны белсәгез! Шулай ерактан килгән Кыш бабайга берәр һөнәреңне күрсәтмичә җибәрү дә оят бит әле! Бар кыюлыгымны җыеп, дүрт юллык шигырь сөйләдем. Сеңлемә дә бу вакыйга бик нык тәэсир иткән, күрәсең, утырган урыныннан тормады да. (Янибызда утырган әниебез генә бертуктамый көлә.)

Ул арада кадерле кунагыбызның китәр вакыты да җитте. Сеңлем белән мине алдына утыртып, теләкләр теләде дә кайтыр юлга чыкты: капкага таба атлады. Безгә кереп баручы Исламгали абый да күрде Кыш бабайны. Бакчага баргач, и мактандык инде башкалар алдында. Ышанмаганнар өчен шаһит та бар: Исламгали абый үзе күргән, янәсе!

...Әлеге хәлне без әле дә көлешеп искә алабыз. Сеңлем дә: «Бер ачып караганда суыткычта ике әфлисун бар иде. Кыш бабай чыгып киткәч, ачып карасам, әлеге әфлисуннардан җилләр искән иде инде», – дип искә төшерә үзенең балачак тәҗрибәсен. Тик без ул вакытта, татлы хыялларга бирелеп, бер кешенең арабызда юклыгына игътибар да итмәгәнбез. Әтиебез юк иде бит! Хәзер тылсымлы кунагыбызның кемлеген аңлагансыздыр инде!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Кыш бабайга хат язмый идек. Бүләкләр дә бирүче булмады. Әтиебез Кыш бабай булгач, аның урманнан төшмәгәнен белә идек. Әллә ниләр бүләк итмәсәләр дә, әтинең янчыгында безгә дигән кәнфитләр булыр иде. Анысын көн дә ашыйсың ла аның, менә мандарин ашау зур бәхет иде безнең өчен. Әнә шулай кечкенәдән тормышка шөкер итеп үстек. Хәзерге балалардан шуның белән аерылабыз да инде без. Алар кебек могҗиза көтмибез, Кыш бабайдан нидер өмет итмибез.

Мин нык салкын көнне һәм аяк астында шыгырдап торган карны яратам. Уртанчы сыйныфларда укыганда, Яңа елда яңгыр яуды. Булган карның эреп бетүе – күңелдә онытылмас хатирә булып калды. Глобаль җылынудыр дип уйлаган идек. Мәктәптә үткән Чыршы бәйрәменә резин итекләр киеп килгәнебез истә калган.

Олырак сыйныфларда Яңа елны дуслар белән каршы ала башладык. Безнең авылда ялгыз торучы әбиләрдән өй сорап тору гадәте бар иде. Әбиләр дә каршы килми – берәр туганына, дустына кунакка китә. Йортын безгә ышанып калдыра иде. Рәхәт чаклар булган ул. Хәер, авыл Яңа елына җитәме соң инде?! Үз Кыш бабаең, Кар кызың, авылдашлар бәйрәм алып бара. Әле ямь өстәп, берничә кеше танымаслык итеп киенеп кереп, биеп күңел ача. Халык 12 тулган вакытта гына өенә кайтып тора да, тагын клубка җыела. Әнә шулай таң ата.

Гаилә, балалар булгач, авылга Яңа ел каршыларга да кайткан юк. Бу бәйрәмне читтә үткәрәсе килми. Аның бар рәхәте дә шундадыр. Быелгы елларда исә күңелгә берни кирәкми. Могҗизалар читтә торсын. Якыннарың янәшәдә булып, авырмасын гына иде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Яңа елны үземне хәтерләгәннән бирле көтеп ала идем. Белмим, әллә тылсымы, әллә тәмле бүләкләре, әллә олысында да, кечесендә дә бәйрәм рухы булуы җәлеп иткән шунда.

Ләкин балалар бакчасына йөргән чактагы бер бәйрәм аеруча тирән «яра» калдырган. Минем әнием укытучы булгач, мәктәптә уза торган Чыршы бәйрәмнәрен калдырганым булмады. Менә шуларның берсе гөрләп торган вакытта, әни белән аның сыйныфына киттек. Шунда барган чакта ни күрим: сыйныф бүлмәләренең берсендә Кыш бабай булып киенеп маташучы укытучы абый басып тора! Мин Кар кызының безгә кадәр килеп җитә алмавын белә идем инде, ел саен балалар бакчасында да, мәктәптәге бәйрәмдә дә ул үзе урынына икетуган апамны җибәрә иде. Ә монда... Кыш бабай да ясалма икән бит!

Бабакайның өлгер булуы, бөтен балалар янына килүе турындагы әкиятләргә шул хәлдән соң ышанмый башладым. Кыш бабайга тагын бераз ышандым ышануын, ләкин аның могҗизалы көче турында ишетергә дә теләмәдем. Ул көнне кәефем кырылган. Аларын ук хәтерләми идем инде, әни сөйләде.

Хәзер менә шул могҗизаларга кабат сабыйларча ышанасы килә. Мөмкин булса, Яңа ел бәйрәмен биш яшьлек Лилия кебек каршылар идем мин. Сәгать уклары кушылганда, әллә нинди зур хыяллар турында уйлап һәм аларның чынга ашуына ихластан ышанып...

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Балачактагы Яңа ел бәйрәме турында язарга утыргач, иң элек балалар бакчасындагы утренник күз алдына килде. Әнинең бәйрәмгә дип алган ап-ак күлмәккә дождик, мишура тегүләре, башка кияргә таҗ ясаулары күз алдында. Калын катыргы кәгазьгә мамык, дождик, пыяладан кечкенә шарчыклар ябыштырылган, тегелгән андый таҗлар – 80 нче елларда туган һәр баланың матур бер истәлегедер инде алар. Чыршы тирәли әйлән-бәйлән әйләнүләр, Кыш бабайны сагынып көтеп торулар, аның һәр хәрәкәтен күзәтү, зур букчасыннан могҗиза көтү.

Соңрак мәктәп елларында мәктәптә һәм авыл клубларында берничә ел рәттән үземә дә Кар кызы булып йөрергә туры килде. Ул елларда авыл клубында да Яңа ел бәйрәмнәре бик күңелле уза торган иде. Бер генә бәйрәм дә әти мәрхүмкәемнең җырларыннан башка узмады. Уеннарда да актив, шат күңелле иде ул. Гомумән, халык та залны шыгрым тутырып килер иде. Кеше күп булганлыктан, көннең һәм клубның салкын-җылы булуына карамастан, ишекләр киереп ачып куелыр иде. Клубта эшләүчеләр стенага, кайсы ел килүенә карап, төрле плакатлар ясап элерләр иде. Концерт, уеннар өлеше беткәч, халык Яңа елны каршы алыр иде дә кабаттан дискотекага җыелыр иде. Әнинең, берничә авыл апасы белән бергә махсус әзерләнеп, танымасыннар өчен, төрле битлекләр, киемнәр киеп, авыл халкын өйдән-өйгә кереп котлап йөрү гадәтләре дә бар иде әле. Соңыннан аларны рәхәт, җылы итеп искә ала идек. Менә шундый күңелле, рәхәт һәм ихлас бәйрәм булып истә калган минем балачак Яңа елым.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Мин балалар бакчасына йөрмәдем. 6 яшьтә, социумнан аерылмасын диптер инде, балалар бакчасына урнаштырдылар мине. Мәктәпкә дә керәсе бар ич, кешеләргә иялашә торырга кирәк. Беренче Яңа елым да шунда булды. Шул ук яшьтә Кыш бабайга ышану белән хушлаштым да. Тәүге журналистик тикшерүем дә шунда булды.

Бәйрәм барышында чыршы утларын яндыру традициясе бар бит. Әнә шул вакытта балалар «утларыңны яндыр!» дип әйтергә тиеш бер мәл була. Исемдә: чыршыга карар урынга, арлы-бирле, уңга-сулга каранып тордым. Шул чагында чыршыдагы гирлянданың утларын тәрбиячебез кабызганын күрдем. Шалт итеп гирляндасын розеткага тыкты да, менә сиңа могҗиза.

Монысына күз йомдым инде. Кыш бабай янына килеп, теләкләр теләү, шигырьләр сөйләү вакыты җитте. Кыш бабайның итәгенә менеп утырдым. Якыннанрак карасам, Кыш бабайның үзебезнең тәрбияче апабыз булуын ачыкладым. «Әй, Кыш бабай түгел бит әле бу. Әйтәм аны Илһамия апа (тәрбиячебез инде бу) баярак туфлиен итеккә алмаштырып утыра иде...» – дип ярып салдым.

Еламадым да, көлмәдем дә. Нәтиҗәләр генә ясалды.

Әмма вакыт узгач, шуны аңладым: тәрбиячеләр балаларга могҗиза тудырырга тырышкан бит. Хәзер дә шулай инде ул. Бүген исә без үзебез дә якыннарыбызга могҗиза тудырыр яшькә җиттек. Бу – авыр хезмәт. Һәм могҗизага тиң хезмәт!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА



Элек чыршы кискәнгә штраф салу гадәте юк иде. Бәлкем, булгандыр да, без генә белмәгәнбездер. Башлангыч мәктәптә укыганда күрше кызы Зилә белән тау башына менеп чыршы кисеп төштек. Аны бизәү күңелле иде. Идән астыннан тартмага тутырылган уенчыкларны күтәреп менәсең, ничектер ул вакытта уенчыклар да матуррак булган кебек.
Кар бөртекләре ясап, тәрәзәгә ябыштырабыз. Мамыкка ялтыравыклар төреп, шуны суга чылатып түшәмгә ата идек. Яңа ел җиткән саен балачак хатирәсе искә төшеп, теге чыршы өчен оят та булып китә. Хәзер мондый эшкә һич тә кул бармас иде.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 389

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+